# ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
# ТУКАЙ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

## КАРАР

«27» 05 2021 ел Яр Чаллы № 1443

Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы Башкарма комитетының 2019 елның 30 маендагы 2035/1 номерлы карарына үзгәрешләр кертү турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, «Дәүләт контролен (күзәтчелеген) һәм муниципаль контрольне гамәлгә ашырганда юридик затларның һәм шәхси шәхси эшмәкәрләрнең хокукларын яклау турында» 2008 елның 26 декабрендәге 294-ФЗ номерлы Федераль законның 6 статьясы 2 өлеше 1 пункты нигезендә Тукай муниципаль районы Башкарма комитеты

**КАРАР БИРӘ:**

1. Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы Башкарма комитетының 2019 елның 30 маендагы 2035/1 номерлы карарына үзгәрешләр кертергә. Тукай муниципаль районы территориясендә гамәлгә ашырыла торган муниципаль контроль төрләре һәм аларны гамәлгә ашырырга вәкаләтле җирле үзидарә органнары исемлеген яңа редакциядә укырга (1 кушымта).
2. Әлеге карарны рәсми хокукый мәгълүмат порталында һәм Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырырга.
3. Әлеге карар үтәлешен контрольдә тотуны үз җаваплылыгымда калдырам.

Башкарма комитет Җитәкчесе А.Р. Хәбибуллин

Тукай муниципаль районы Башкарма комитетының 2021 елнын 27 маендагы 1443 номерлы карарына 1 кушымта

## Тукай муниципаль районы территориясендә гамәлгә ашырыла торган муниципаль контроль төрләре һәм аларны гамәлгә ашырырга вәкаләтле җирле үзидарә органнары исемлеге

| Тәртип саны | Муниципаль контроль төр исеме | Муниципаль контрольнең тиешле төрен гамәлгә ашыру буенча вәкаләтләр бирелгән Тукай муниципаль районы җирле үзидарә органы исеме (урнашу урыны, телефоны) | Муниципаль контрольнең тиешле төрен гамәлгә ашыруны тәэмин итә торган Тукай муниципаль районы җирле үзидарә органнарының структур бүлекчәләре яисә вазыйфаи затлары исеме (урнашу урыны, телефоны) | Муниципаль контрольнең тиешле төрен гамәлгә ашыруның административ регламентын раслау турында Тукай муниципаль районының муниципаль норматив хокукый акты исеме һәм реквизитлары |
|---|---|---|---|---|
| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 |
| 1. | Муниципаль җир контроле | Тукай муниципаль районы мөлкәт һәм җир мөнәсәбәтләре палатасы,<br>Яр Чаллы ш.,<br>М. Җәлил пр., 46.<br>Тел. (8552) 70-17-83 | Тукай муниципаль районы мөлкәт һәм җир мөнәсәбәтләре палатасы рәисе урынбасары,<br>Яр Чаллы ш.,<br>М. Җәлил пр., 46.<br>Тел. (8552) 70-17-83 | Тукай муниципаль районы Башкарма комитеты Җитәкчесенең 2017 елның 29 июнендәге 1860 номерлы карары |
| 2. | Тукай муниципаль районы территориясендә гомумтаралган файдалы казылмалар чыгарганда һәм казылмалар чыгару белән бәйле булмаган җир асты корылмаларын төзегәндә, җир асты байлыкларын файдалануга һәм саклауга муниципаль контроль | Тукай муниципаль районы мөлкәт һәм җир мөнәсәбәтләре палатасы,<br>Яр Чаллы ш.,<br>М. Җәлил пр., 46.<br>Тел. (8552) 70-17-83 | Тукай муниципаль районы мөлкәт һәм җир мөнәсәбәтләре палатасы рәисе урынбасары,<br>Яр Чаллы ш.,<br>М. Җәлил пр., 46.<br>Тел. (8552) 70-17-83 | Тукай муниципаль районы Башкарма комитетының 2021 елның 20 апрелендәге 1191 номерлы карары |